**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районы**
**Югары Шепкә авыл җирлеге Советы**

**КАРАРЫ**

**№ 83** **«28» февраль 2023 ел**

**«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында»2020 елның “29”декабрендәге 19 номерлы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт милкен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 05 декабрендәге 512-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә,Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Шепкә авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1.«Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлегенең муниципаль мөлкәтен хосусыйлаштыру тәртибе һәм шартлары турында нигезләмәне раслау хакында» 2020 елның “29”декабрендә 19 номерлы Зәй муниципаль районы Югары Шепкә авыл җирлеге Советы карарына (2021 елның 20 апрелендәге 27 номерлы, 2022 елның 28 мартында 51 номерлы, 2022 елның 23 ноябрендә 70номерлы карарлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән),
6.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:
«6.3.Ачык тәкъдим аша сатуда катнашу өчен,дәгъва итүче түбәндәге күләмдә алдан акча(задаток)кертә:
100 миллион һәм аннан да күбрәк сумманы тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 20 процентын;
100 миллион сумнан кимрәк тәшкил иткән муниципаль мөлкәтне сату турында мәгълүмати хәбәрдә күрсәтелгән башлангыч бәянең 10 процентын.».
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU), җирлекнең торак пунктлары территориясендәге махсус мәгълүмат стендларында һәм Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Л.М.Камалиева**